ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.08.2020 ел Ямбулат авылы № 13

Татарстан Республикасы Президенты сайлауларын һәм
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча сайлау алды
агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган
урыннар билгеләү хакында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясының 8 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 13 сентябрендә Татарстан Республикасы Президентын һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Башка йортларда, корылмаларда, объектларда һәм биналарда агитация материаллары милекчеләр, әлеге объектларның хуҗалары ризалыгы белән эленә (ябыштырыла, урнаштырыла).

3. Һәйкәлләрдә, обелискларда, биналарда, корылмаларда һәм тарихи, мәдәни һәм архитектура кыйммәтләре булган биналарда, шулай ук сайлау комиссияләре биналарында һәм бүлмәләрендә, тавыш бирү өчен бүлмәләрдә һәм аларга керү урыннарыннан 50 метрдан кимрәк арада агитация материалларын эләргә (ябыштырырга, урнаштырырга) тыела.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов

Ямбулат авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 10 августындагы
13 нче номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

2020 елның 13 сентябрендә Татарстан Республикасы Президентын һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар исемлеге

| т/б № | Агитацион басма материаллар элү өчен махсус урын булган адрес | Элү урынының исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), стенд (бина диварындагы игъланнар тактасы, фойеда һ. б.) |
|---|---|---|
| 1 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Ямбулат авылы, Үзәк урам, 5 йорт | Мәгълүмати стенд,<br>бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 2 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Ямбулат авылы, Казан урамы, 2А йорты | Мәгълүмати стенд,<br>бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 3 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Крестниково авылы, Казан урамы, 8 йорт | Мәгълүмати стенд |
| 4 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Ямбулат авылы, Коновалов урамы, 57 йорт | Мәгълүмати стенд,<br>бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 5 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Казан урамы, 4 йорт | Мәгълүмати стенд,<br>бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 6 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Крестниково авылы, Үзәк урам, 7 йорт | Бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 7 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Крестниково авылы, Үзәк урам, 58А йорты | Бина стенасында белдерүләр тактасы |
| 8 | ТР, Югары Ослан районы,<br>Ямбулат авылы, Коновалов урамы, 25А йорты | Бина стенасында белдерүләр тактасы |

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов